Урманасты Шынталы  мәктәбенең беренче пионерларыннан берсе 1924 нче елда туган  **Билалова(Бәширова) Галия апа** сөйләвеннән.*(Музей материалларыннан алынды. Галия апа 2015 елда бакыйлыкка күчкән)*

- *Мин 1933 нче елда пионер сафларына кабул ителдем. Бу елларда пионер* оешмасы яңа оешып килә иде. Безнең мәктәпнең үзенең кечкенә байрагы һәм барабаны бар иде. Галстук таккан көн хәтеремдә иң тантаналы көннәрнең берсе булып калды. Галстукны кызыл материядән үзебез ясадык. Кайбер балаларның әти-әниләре галстук тагуны тыйдылар. Алар өйләренә кайтканда галстукларын яшереп куя торган булдылар.
Мин отрядта звено вожатые булдым. Үзенә күрә планнар төзеп, эшне тырышып оештыра идем. Бәйрәм көннәрендә урамнан җырлар җырлап үтә идек. Колхозга концерт куярга бара идек. Укытучылар җитешмәгәнгә күрәдер, безгә вожатыйлар булып эшләргә туры килде.